**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 14** **03.07.2020 ел**

**Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 05.10.2007 ел 25 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

a. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017 елның 25 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

a. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Яңа Әлем авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык Д.М.Әнварова